| | |
|---|---|
| **ГЛАВА**<br>**Крындинского сельского поселения**<br>**Агрызского муниципального района**<br>**Республики Татарстан** | **Татарстан Республикасы**<br>**Әгерҗе муниципаль районы**<br>**Кырынды авыл җирлеге**<br>**БАШЛЫГЫ** |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

15.11.2024 Кырынды авылы № 3

Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм кулану мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Кырынды авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Еленовский торак пунктында гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Кырынды авыл җирлеге Уставының 14 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Кырынды авыл җирлеге башлыгы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Кырынды авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Еленовский торак пунктында гражданнардан үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 2024 елның 27 ноябренә 08 сәг 00 мин билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорау итеп расларга: «2025 елда Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Кырынды авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Еленовский торак пункты территориясендә, I төркем инвалидлардан, ялгыз өлкән яшьтәге (80 яшькә җиткән) гражданнардан, көндезге формада белем алучы студентлардан, Россия Армиясе сафларында вакытлы хезмәткә чакырылган затлардан, ирекләреннән мәхрүм итү урыннарында торучы затлардан, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучылардан (контракт буенча хәрби хезмәткәрләрне, мобилизацияләнгән, ирекле) һәм аларның бергә яшәүче гаилә әгъзаларын (ата-аналар, хатын, балигъ булган балалар) тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәм балигъ булган һәр кешедән 500 сум күләмендә узара салым чаралары җыены кертүгә һәм алардан җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен файдалануга ризамы:

1. Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Еленовский поселокның Красная ур. юлларны вак таш сатып алу һәм салу һәм автомобиль юлларын карап тоту буенча башка чыгымнар).

2. Торак пункт территориясен төзекләндерү (үлән чаптыру, юлларны кардан чистарту һәм торак пункт территориясен төзекләндерү буенча башка чыгымнар).

«РИЗА» «КАРШЫ»

3. Гражданнар җыенын Татарстан Республикасы, Әгерҗе районы, Еленовский поселогы, Красная ур., 13 нче йорт территориясендә үткәрергә.

4. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Кырынды авыл җирлеге башкарма комитетына гражданнар җыенын оештыруны һәм үткәрүне йөкләргә.

5. Әлеге карарны Кырынды авыл җирлегенең мәгълүмат стендында элеп халыкка җиткерергә, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтына урнаштырырга (https://agryz.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (https://pravo.tatarstan.ru) бастырырга.

6. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

7. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп тотуны үз өстемә алам.

Совет Рәисе,
авыл җирлеге башлыгы Р.Р. Мауликаев